ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 16 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты дүртенче абзацының, 61 статьясындагы 3 пунктының, 77 статьясындагы 3 пункты алтынчы абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш) гамәлдә булуын 2016 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**2 статья**

2015 елда түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты җыелма бюджет язмасы) күрсәткечләренә 2016 һәм 2017 еллар күрсәткечләре өлешендә үзгәрешләр кертелми;

2) 2016 һәм 2017 елларга бюджет йөкләмәләре лимитлары Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларын баш бүлүчеләргә) җиткерелми;

3) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларын алучы) тарафыннан 2016 һәм (яисә) 2017 елларда түләнергә тиешле йөкләмәләр кабул ителгән шартнамәләр (килешүләр) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучыга (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты акчаларын алучыга) күрсәтелгән елларга бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелмәүгә бәйле рәвештә аның инициативасы белән өзелми;

4) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы исеменнән 2016 елда товарлар кайтару буенча тиешле йөкләмәләр өчен түләүне күздә тота торган шартнамәләр (килешүләр) төзү рөхсәт ителә;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан арткан чорга Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен барлыкка китерүгә бәйле башка шартнамәләр (килешүләр) төзү рөхсәт ителә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 22 апреле
№ 26-ТРЗ